Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының ундүртенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 август, 2021 ел № 96

2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына физик затлар керемнәренә салымнан Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетына күчерелә торган өстәмә норматив белән муниципаль районнарның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотация алмаштыруны килештерү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 138 статьясындагы 5 пункты нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетына физик затлар керемнәренә салымнан 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына күчерелгән өстәмә норматив белән муниципаль районнарның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне алмаштыруны килештерергә.
2. Карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.
3. Питрәч муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисенә әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов